СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.09.24г № 49/2

На № _________ от ____________

# КАРАР

## «Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына («Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 27 маендагы 46/3 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлек 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен акчалата бүләкләү билгеләргә:

- Муниципаль берәмлек Башлыгына 134 580 сум күләмендә;
- муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарына, контроль-хисап палатасы рәисенә 59 841 сум күләмендә.

Шул ук вакытта муниципаль берәмлек Башлыгының айлык акчалата түләүләренең җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән арта алмый. Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары һәм контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләүләренең 0,55 күләменнән артмаска тиеш.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров